ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

23 12 2019 г. № 892

Ике һәм аннан күбрәк сөт сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерларын карап тоту өчен терлек азыгы һәм кысыр таналар сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы, «Крестьян (фермер) хуҗалыгы турында» 2003 елның 11 июнендәге 74 номерлы Федераль законның 2 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2018 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы карарын үтәп, Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районында авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру һәм хуҗалык итүнең кече формаларын үстерү чаралары турында» 2017 елның 14 апрелендәге 22 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Түбән Кама муниципаль районы Советының Түбән «Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районының 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына бюджеты турында» 2018 елның 19 декабрендәге 76 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2019 елның 20 декабрендәге 80 номерлы карары белән, карар бирәм:

1. Ике һәм аннан күбрәк сөт сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерларын карап тоту өчен терлек азыгы һәм кысыр таналар сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен 1-нче кушымта нигезендә расларга.

2. Ике һәм аннан күбрәк сөт сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерларын карап тоту өчен терлек азыгы һәм кысыр таналар сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү турында карар кабул итәргә вәкаләтле комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны үтәүне контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Г. Нигъмәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 23-нче декабрь
892-нче номерлы карары белән расланган
1-нче кушымта

Ике һәм аннан күбрәк сөт сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерларын карап тоту өчен терлек азыгы һәм кысыр таналар сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советының бюджет турындагы карарын гамәлгә ашыру максатларында кабул ителде һәм Түбән Кама муниципаль районы бюджетыннан, субсидия алучының әлеге Тәртип таләпләренә (алга таба – субсидияләр алучылар) туры килгәндә, Түбән Кама муниципаль районы составына керүче һәм Түбән Кама муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы (алга таба – шәхси ярдәмче хуҗалык), авыл торак пунктларында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарга кысыр таналар һәм (яки) беренче тапкыр бозаулаган таналар, сөт сыерларын карап тоту өчен азык сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү процедурасын билгели. Шәхси ярдәмче хуҗалык әлеге тәртиптә «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль законда бирелә торган мәгънәдә кулланыла.

1.2. Субсидияләр бирүнең максаты - сөт сыерларының баш санын саклап калуны һәм терлекчелек продукциясен җитештерүне тәэмин итү, гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалыкларында сөт сыерларының баш санын арттыруны стимуллаштыру.

1.3. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) бюджет акчаларын алучы буларак, төп җаваплы оештыручы булып тора. Субсидия алучылар тапшырган документларны кабул итү буенча Башкарма комитетның вәкаләтле структур бүлекчәсе булып, Башкарма комитетның җирле үзидарә органнары белән үзара бәйләнеш һәм муниципальара хезмәттәшлек бүлеге (алга таба - бүлек) тора.

1.4. Субсидия гариза нигезендә бирелә.

2. Субсидияләр бирүнең максатлары, шартлары һәм тәртибе

2.1. Кысыр таналар һәм (яки) беренче тапкыр бозаулаган таналар сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплау.

2.1.1. Кысыр таналар һәм (яки) беренче тапкыр бозаулаган таналар баш санын сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр алуга сайлап алу критерийлары булып тора:

рөхсәт ителгән җир кишәрлекләреннән файдалану төрләре классификаторы нигезендә, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән яки сатып алынган җир кишәрлеге булу;

бер үк вакытта милек хокукында һәм (яки) башка хокукта булган җир кишәрлекләренең гомуми мәйданы ике гектардан артмаска тиеш, шул исәптән торак пункт чикләрендә - бер гектардан;

агымдагы финанс елында кысыр таналар һәм (яки) беренче тапкыр бозаулаган таналар баш санын сатып алуны раслаучы документлар һәм сатып алынган терлеккә ветеринария документлары булу;

субсидияләр алынган көннән соң биш ел дәвамында сатып алынган кысыр таналар һәм (яки) беренче тапкыр бозаулаган таналар баш санын саклап калу буенча йөкләмә (субсидияләр алу көне булып, шәхси ярдәмче хуҗалыкларның банк счетына акча керү тора);

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Башкарма комитеты җитәкчесе имзасы белән расланган һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы имзасы һәм мөһере белән расланган, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының авыл җирлеге башлыгы тарафыннан имзаланган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөт юнәлешендәге мини-фермалар төзүгә киткән чыгымнарның бер өлешен каплау өчен, Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү өчен белешмә – хисап күчермәләрен тапшыру.

2.1.2. Субсидия шәхси ярдәмче хуҗалык субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айның беренче числосына түбәндәге таләпләргә туры килгән очракта бирелә:

законнарда билгеләнгән тәртиптә исәпкә алу кенәгәсендә теркәлү һәм Түбән Кама муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып бару;

субсидия алучылар - физик затлар банкротлык стадиясендә яки банкрот булырга тиеш түгел;

субсидия алучылар әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларга Түбән Кама муниципаль районының башка норматив хокукый актлары нигезендә Түбән Кама муниципаль районы бюджетыннан акча алучылар булып торырга тиеш түгел;

Әлеге Тәртипнең 2.1.3 пункты нигезендә, юридик зат статусына ия авыл хуҗалыгы оешмаларыннан һәм (яисә) крестьян (фермер) хуҗалыкларыннан агымдагы финанс елында кысыр таналар һәм (яки) беренче тапкыр бозаулаган таналар товар баш санын сатып алу.

2.1.3. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидия яңа сатып алынган бер баш терлеккә исәпләп бер тапкыр бирелә – товар кысыр таналарга һәм (яки) беренче тапкыр бозаулаган таналарга - 30,0 мең сум.

2.1.4. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр алу өчен Башкарма комитетка түбәндәге документларны тапшыра:

субсидия алган көннән соң биш ел эчендә сатып алган кысыр таналарның һәм беренче тапкыр бозаулаган таналарның баш санын саклап калу йөкләмәсен, почта

адресын, үзенең түләү реквизитларын күрсәтеп, 1 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча, түбәндәгеләрне үз эченә алган, субсидия бирү турында гариза:

субсидия алучының әлеге Тәртипнең 2.1.2 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат;

субсидия алуга бирелгән шәхси мәгълүматка караган мәгълүматны эшкәртүгә ризалык һәм субсидия бирү документларын карауда катнашучы затларның аңа керү мөмкинлеге;

шәхси ярдәмче хуҗалыкларны алып бару өчен файдаланыла торган җир кишәрлегенә хокук билгеләү документы (таныклык) күчермәсе, яисә Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе аша алынган Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

юридик зат статусына ия авыл хуҗалыгы оешмаларыннан агымдагы финанс елында кысыр таналар һәм (яисә) беренче тапкыр бозаулаган таналар товар баш санын сатып алуга чыгымнарны раслаучы документлар (сату-алу шартнамәләренең, товар-транспорт накладнойларының, банк-түләүче раслаган түләү документларының һәм (яки) керем-касса ордерларының, сатып алына торган кысыр таналарның (яше 21 айдан, тере авырлыгы кимендә 430 килограмм) һәм беренче тапкыр бозаулаган таналарның (яше 27 айдан (36 айдан да өлкәнрәк түгел), тере авырлыгы 450 килограммнан да ким булмаган) яшен, исемен күрсәтеп, авыл хуҗалыгы терлекләрен сатып алуга кабул итү-тапшыру актларының төп нөсхәләре һәм күчермәләре. Чагыштырганнан соң документларның төп нөсхәләре мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарыла, ә аларның күчермәләре бүлек башлыгы (яисә башка вәкаләтле зат) һәм субсидия алучы тарафыннан раслана;

терлек сатып алу көнендә рәсмиләштерелгән кысыр таналар һәм (яки) беренче тапкыр бозаулаган таналар баш санын сатып алуга ветеринария белешмәләре һәм таныклыклар күчермәләре;

сатып алынган терлекне исәпкә алу фактын раслаучы шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу кенәгәсеннән өземтә.

Шәхси ярдәмче хуҗалыкларның баш санын саклап калу турында кабул ителгән йөкләмә срогы чыкканчы, авыру нәтиҗәсендә, сатып алынган кысыр таналар һәм (яки) беренче тапкыр бозаулаган таналар товар баш саны кырылу яки мәҗбүри сую очрагында, Башкарма комитетка билгеләнгән тәртиптә ветеринария белешмәләре һәм терлекләрне браковкалау актлары тапшырыла.

Тапшырылган документларның күчермәләре субсидия алучылар тарафыннан раслана.

Субсидия бирүнең нәтиҗәлелеге күрсәткече - сатып алынган терлекләрнең баш санын саклап калу.

2.2. Сөт сыерларын карап тоту өчен азык сатып алуга чыгымнар өлешен каплау.

2.2.1. Субсидия алу өчен шәхси ярдәмче хуҗалыкларны сайлап алу критерийлары булып тора:

рөхсәт ителгән җир кишәрлекләреннән файдалану төрләре классификаторы нигезендә, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән яки сатып алынган җир кишәрлегенең булу;

бер үк вакытта милек хокукында һәм (яки) башка хокукта булган җир кишәрлекләренең гомуми мәйданы ике гектардан артмаска тиеш, шул исәптән то-рак пункт чикләрендә - бер гектардан;

агымдагы финанс елының 1 гыйнварына шәхси ярдәмче хуҗалыкларның исәпкә алу буенча хуҗалык кенәгәләрендә язу нигезендә сыерларның баш саны булу;

агымдагы финанс елында сыерларны тупас азык (печән, салам), концентрацияләнгән азык (солы, арпа, көрпә, кукуруз), сыерлар асраугa (алга таба – терлек азыгы) чыгымнарга кертелгән премикслар сатып алу буенча чыгымнарны гамәлгә ашыру.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Башкарма комитеты җитәкчесе имзасы белән расланган һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының  Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы имзасы һәм мөһере белән расланган, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының авыл җирлеге башлыгы тарафыннан имзаланган,  шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөт юнәлешендәге мини-фермалар төзүгә киткән чыгымнарның бер өлешен каплау өчен, Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү өчен белешмә – хисап күчермәләрен тапшыру.

2.2.2. Субсидия шәхси ярдәмче хуҗалык субсидия бирү планлаштырыла торган айның беренче числосына түбәндәге таләпләргә туры килгән очракта бирелә:

законнарда билгеләнгән тәртиптә исәпкә алу кенәгәсендә теркәлү һәм Түбән Кама муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып бару;

субсидия алучылар - физик затлар банкротлык стадиясендә яки банкрот булырга тиеш түгел;

субсидия алучылар әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән максатларга Түбән Кама муниципаль районының башка норматив хокукый актлары нигезендә Түбән Кама муниципаль районы бюджетыннан акча алучылар булып торырга тиеш түгел;

Әлеге Тәртипнең 2.1.3 пункты нигезендә, юридик зат статусына ия авыл хуҗалыгы оешмаларыннан һәм (яисә) крестьян (фермер) хуҗалыкларыннан агымдагы финанс елында кысыр таналар һәм (яки) беренче тапкыр бозаулаган таналар товар баш санын сатып алу.

2.2.3. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларга Субсидия бер сыерга 10,0 мең сум исәбеннән бирелә.

2.2.4. Шәхси ярдәмче хуҗалыклар субсидияләр алу өчен Башкарма комитетка түбәндәге документларны тапшыра:

агымдагы елның 31 декабренә кадәр сыерларның баш санын саклап калу йөкләмәсен, почта адресын, үзенең исән-хисап счетын һәм банк реквизитларын күрсәтеп, 2 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча субсидия бирү турында гариза, шул исәптән субсидия алучы турында түбәндәге мәгълүмат:

әлеге Тәртипнең 2.1.2 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе;

әлеге Тәртип таләпләре нигезендә, Түбән Кама муниципаль районының башка норматив хокукый актлары нигезендә Түбән Кама муниципаль районы бюджетыннан акча алучы булып тормый;

субсидия алуга бирелгән шәхси мәгълүматка караган мәгълүматны эшкәртүгә ризалык һәм субсидия бирү документларын карауда катнашучы затларның аңа керү мөмкинлеге;

шәхси ярдәмче хуҗалыкларны алып бару өчен файдаланыла торган җир кишәрлегенә хокук билгеләү документы (таныклык) күчермәсе, яисә Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе аша алынган Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

сыерлар булу фактын раслый торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу буенча хуҗалык кенәгәсеннән өземтә.

Контроль максатларында Башкарма комитет шәхси ярдәмче хуҗалыклар - субсидияләр күчерелгән датага терлек булу турында электрон хуҗалык кенәгәсеннән субсидия алучылар буенча хисап төзергә хокуклы.

Шәхси ярдәмче хуҗалыкларның баш санын саклап калу турында кабул ителгән йөкләмә срогы чыкканчы, авыру нәтиҗәсендә, сыерлар кырылу яки мәҗбүри сую очрагында, Башкарма комитетка билгеләнгән тәртиптә ветеринария белешмәләре һәм терлекләрне браковкалау актлары тапшырыла.

Тапшырылган документларның күчермәләре субсидия алучылар тарафыннан раслана.

Субсидия бирүнең нәтиҗәлелеге күрсәткече – 2020 елның 31 декабренә сыерлар баш санын саклап калу. Шартнамәдә билгеләнгән форма буенча нәтиҗәлелек күрсәткечләрен үтәү турындагы хисап Башкарма комитетка 2021 елның 1 февраленә кадәр тапшырыла.

2.3. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тартуга нигез булып тора:

субсидия алучының әлеге тәртип таләпләренә туры килмәве;

әлеге тәртиптә каралган документларны яки мәгълүматларны тапшырмау яки тулысынча тапшырмау;

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы.

2.4. Мөрәҗәгать итүче гражданнар гамәлдәге законнар нигезендә субсидия бирүдән баш тарту турындагы карарларга шикаять бирергә хокуклы.

## 3.Түбән Кама муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы мәсьәләләрне карау һәм карарлар кабул итү тәртибе

3.1. Субсидияләр бирү максатларында, бүлек авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары аша субсидия алучыларга хәбәр итә.

Документлар түбәндәгеләрне башкару өчен бүлеккә тапшырыла:

- субсидияләр бирү турында гаризаны ул кергән көнендә нумерланырга, тегелергә һәм мөһер белән беркетелергә тиеш журналда терки һәм әлеге Тәртипнең 2 нче бүлеге нигезендә тапшырылган документларны карый;

- әлеге Тәртипнең 2 бүлегендә күрсәтелгән документларның булуын, документлардагы белешмәләрнең булуын һәм дөреслеген тикшерә;

- субсидия алучының әлеге тәртип таләпләренә туры килүен тикшерә;

- Тәртипнең 2 бүлегендә күрсәтелгән документлар нигезендә, субсидия алуга җыелма белешмә-хисаплар төзиләр.

3.2. Гаризаны теркәгән көннән соң 5 көн эчендә Бүлек документларны карый, ике һәм аннан күбрәк сөт сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыер-

ларын карап тоту өчен терлек азыгы һәм кысыр таналар сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү турында карар кабул итәргә вәкаләтле комиссия карарын кабул итүне һәм шулай ук субсидия алучылар белән субсидия бирү турында шартнамәләр төзүне тәэмин итә. Субсидия алучылар тарафыннан тапшырылган документлар, кире кайтарылырга тиешле чыгымнарның белешмә-хисаплары, комиссия карары һәм субсидияләр бирү турында төзелгән шартнамәләр Бүлек тарафыннан субсидияләр күчерү өчен бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә тапшырыла.

## 4.Субсидияләр күчерү тәртибе һәм аларны бирү шартларын үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру

4.1. Түбән Кама муниципаль районы бюджетыннан субсидия субсидияләр бирү турындагы шартнамә нигезендә бирелә.

Субсидия бирү турындагы шартнамәдә субсидияне күчерү шартлары, субсидия хисабына түләнергә тиешле алынып бетмәгән керемнәр һәм чыгымнар турында хисабын субсидия алучы тарафыннан бирү тәртибе, шулай ук әлеге төр шартнамә өчен билгеләнгән башка мөһим шартлар карала.

Субсидия күчерү срогы бюджет акчаларын баш бүлүчегә лимитлар җиткергәннән һәм әлеге Тәртипнең 3.2 пункты нигезендә документлар тапшырганнан соң 5 календарь көн эчендә билгеләнә. Субсидия субсидия алучының банк счетына күчерү юлы белән бирелә.

4.2. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган үзенең шәхси счетыннан субсидия алучыларның банк счетларына акча күчерүне гамәлгә ашыра. Бюджет акчаларын баш бүлүче, аларны алучылар тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне контрольдә тота. Күрсәтелгән контроль шулай ук эчке муниципаль финанс контроль органнары һәм тышкы муниципаль финанс контроль органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Субсидия алучылар субсидияләрдән файдалану һәм аларны бирү шартларын үтәү турында хисапны субсидияләр бирү турында шартнамәдә билгеләнгән формалар буенча һәм срокларда тапшыралар.

4.4. Субсидия алучы бюджет акчаларын баш бүлүче алдында субсидия бирү турында шартнамәдә билгеләнгән формалар һәм срокларда субсидияне файдалану турында хисап тота.

4.5. 2021 елның 1 февраленә кадәр субсидия алучы бүлеккә субсидияләрдән файдалану турында хисап тапшыра. Хисапның эчтәлеге килешү белән билгеләнә.

Хисап составына субсидия алучы чыгымнарны раслаучы документларны кертә. Ике һәм аннан күбрәк сөт сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерларын карап тоту өчен терлек азыгы һәм кысыр таналар сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү турында карар кабул итәргә вәкаләтле комиссия күрсәтелгән хисапны бюджет акчалар файдалануның дөреслеге, нәтиҗәлелеге һәм максатчан файдалану билгеләре буенча бәяли. Хисап күрсәтелгән таләпләргә туры килгән очракта, комиссия аны килештерә һәм бухгалтер исәбе һәм хисаплылык бүлегенә тапшыра.

Субсидия алучы хисапны сыйфатлы һәм вакытында төзү, субсидия бирү шартларын һәм максатларын үтәү, шулай ук тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплы.

4.6. Субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын үтәмәве яки тиешенчә үтәмәве бюджет акчаларыннан максатчан файдаланмау булып тора һәм Россия Федерациясе законнары белән җаваплылыкка тартыла.

4.7. Субсидияләр бирү шартларын бозу ачыкланган яки субсидияләр алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар бирелгән очракта, бюджет акчаларын баш бүлүченең язма таләбе буенча 30 көн эчендә субсидия суммасының 10% ы күләмендә штраф салынып, Түбән Кама муниципаль районы бюджетына субсидия алучы тарафыннан кире кайтарылырга тиеш. Пеня субсидия суммасын кире кайтару срогы чыккан һәр көн өчен исәпләнә һәм кире кайтарылырга тиешле субсидия суммасыннан Россия Федерациясе Үзәк Банкының рефинанслау ставкасының пеня түләү датасына гамәлдә булган өч йөздән күләмдә билгеләнә.

4.8. Субсидия алучы әлеге Тәртипнең 4.7 пунктында билгеләнгән вакытка күчермәсә, субсидия суммасын бюджет акчаларын баш бүлүче гамәлдәге законнарда һәм субсидия бирү турында шартнамәдә билгеләнгән неустойканы исәпләп суд тәртибендә түләттерә.

4.9. Субсидия алучылар тарафыннан бирелә торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидия алучыларга йөкләнә.

4.10. Субсидия алучыларга чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү максатларында, бирелгән акчалар хисабына чит ил валютасы сатып алу тыела, югары технологияле чит ил җиһазларын, чималны һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (җибәргәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләр, шулай ук субсидияләр бирү тәртибен җайга сала торган муниципаль хокукый актлар, норматив хокукый актлар белән билгеләнгән әлеге акчаларны бирү максатларына ирешү белән бәйле башка операцияләрдән тыш.

4.11. Субсидия алучылар субсидияләрне максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тәэмин итәргә тиеш. Шартнамәгә кул кую белән субсидия алучы алына торган субсидияләрнең максатчан һәм нәтиҗәле кулланылуын тәэмин итү йөкләмәсен кабул итә һәм муниципаль финанс контроле органы һәм идарәсе тарафыннан субсидия алучының субсидия алу шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүне гамәлгә ашырырга ризалык белдерә.

Ике һәм аннан күбрәк сөт сыерлары булган
шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт
сыерларын карап тоту өчен терлек азыгы
һәм кысыр таналар сатып алуга
чыгымнарның бер өлешен каплауга
субсидияләр бирү тәртибенә
1 нче кушымта

Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе
______________________________

ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БЮДЖЕТЫННАН СУБСИДИЯ АЛУГА
ГАРИЗА

________________________________________________________________________________
(субсидия алучының исеме)

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Ике һәм аннан күбрәк сөт сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерларын карап тоту өчен терлек азыгы һәм кысыр таналар сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның «___» __________ __ номерлы карарын тормышка ашыру максатларында, ________________________ _____________сум субсидия бирүне сорый.

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Исеме | |
| 2 | ИНН | |
| 3 | Фактик адрес | |
| 4 | Элемтә өчен телефон/факс | |
| 5 | Почта адресы | |
| 11 | Банк реквизитлары | |

Субсидия бирүнең максатлары, шартлары һәм тәртибе белән таныш һәм килешәм. Бу хакта декларация ясыйм_______________елларда мин банкротлык процедурасы статиясендә тормыйм яки банкрот түгел, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның «___» ___________ __ номерлы карары белән расланган ике һәм аннан күбрәк сөт сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерларын карап тоту өчен терлек азыгы һәм кысыр таналар сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе таләпләре нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы бюджетыннан акча алучы түгел.

__________________________ ____________________________
(ФИО) Имза

Дата

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 23-нче декабрь
892-нче номерлы карары белән расланган
2-нче кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының ике һәм аннан күбрәк сөт сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерларын карап тоту өчен терлек азыгы һәм кысыр таналар сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү турында карар кабул итәргә вәкаләтле комиссия составы

| | | |
|---|---|---|
| Беляев Радмир Илдар улы | - | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе; |
| Нигъмәтҗанов Альфред Галим улы | - | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Хәйретдинов Марсель Мәсхүт улы | - | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль заказ бүлеге башлыгы; |
| Морозова Елена Александровна | - | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының җирле үзидарә органнары һәм муниципальара хезмәттәшлек бүлеге башлыгы; |
| Мәүләвиев Рөстәм Илгизәр улы | - | Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Түбән Кама муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча). |